БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 июнь 2024 ел № 255

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2023 елның 14 декабрендәге 228 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының маневрлы муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 4.7 пунктча белән тулыландырырга:

«4.7. Торак биналар биргән өчен түбәндәге очракларда түләү алынмый:

4.7.1. Гражданнарның бердәнбер торак урыннары гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксызга чыккан;

4.7.2. Гражданнарның социаль наем шартнамәсе буенча биләгән торак биналары урнашкан йортны капиталь ремонтлауга яисә реконструкцияләүгә бәйле рәвештә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин